ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планын (кушымта итеп бирелә) расларга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 22 ноябре
№ 17-VII ДСП

2024 елның 22 ноябрендәге 17-VII ДСП номерлы
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Президиумы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәр | Гамәлгә ашыру буенча чаралар | Үтәү срогы | Башкару өчен җаваплы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Меңләгән татарстанлы махсус хәрби операция барышында Ватаныбыз иминлеге һәм бәйсезлеге өчен үз-үзен аямыйча көрәшә. Хәрби бурычларын намус белән үтәп, безнең сугышчылар батырлык, кыюлык һәм каһарманлык үрнәкләре күрсәтә.<br>«Барысы да фронт өчен! Барысы да Җиңү өчен!» дигән мәгълүм сүзләр бүген янә әһәмият ала. Килеп туган кыенлыкларга каршы республика халкы тагын да берләшү һәм гражданнар арасында татулыкны ныгыту, фронтка, чиктәш төбәкләрдә яшәүче ватандашларыбызга, шулай ук шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә ярдәм күрсәтү белән җавап бирә. | 1.1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә гуманитар ярдәм җыю һәм аны җибәрү эшен оештыру, шулай ук Луганск Халык Республикасы һәм Донецк Халык Республикасы халкына спонсор ярдәме күрсәтү. | 2024, 2025 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләре |
| 2. | Без, һичшиксез, Җиңү яулаячакбыз, геройларыбыз туган нигезләренә әйләнеп кайтачак. Аларның тыныч тормышка керешүе өчен кирәк булган барлык шартларны тудырырга тиешбез. Бу исә тулы бер мәсьәләләр комплексын хәл итүне таләп итәчәк. Шуларның | 2.1. «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы белән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләрне | 2024, 2025 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (С.М. Захарова) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | иң әһәмиятлеләре махсус хәрби операция ветераннарының җәмгыять таләпләренә җайлашуы һәм аларны тернәкләндерү, эшкә урнаштыру, барлык ярдәм чараларының кичекмәстән күрсәтелүе белән бәйле.<br>Бу эшкә барлык дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, республика предприятиеләре һәм оешмалары, шулай ук махсус хәрби операция ветераннарының быел оештырылган ассоциациясе һәм башка иҗтимагый оешмалар җәлеп ителергә тиеш.<br>Депутатлар корпусына, шул исәптән тиешле закон башлангычларын эшләү буенча да, бу эшкә актив керешүләрен сорыйм. | хәл итүдә хезмәттәшлек.<br><br>2.2. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә, Россия Федерациясенең яңа субъектларында яшәүчеләргә, Татарстан Республикасында вакытлыча яшәүчеләргә ярдәм чараларына, законнарны алга таба камилләштереп, мониторинг ясау.<br><br>2.3. «ТНВ» депутат төркеме утырышында «Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм чаралары күрсәтү турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>2.4. «Мәҗбүри медицина иминияте кысаларында махсус хәрби операция ветераннарына медицина ярдәме һәм медицина реабилитациясе күрсәтү турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>2.5. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә, Россия Федерациясенең яңа субъектларында яшәүчеләргә, Татарстан Республикасында вакытлыча яшәүчеләргә ярдәм чаралары турындагы законнарны үтәү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан халыкны кабул итүләр. | <br><br>2024, 2025 еллар дәвамында<br><br>2025 елның I кварталы<br><br>2025 елның ноябре<br><br>2024, 2025 еллар дәвамында | <br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары<br><br>«ТНВ» депутат төркеме (А.Р. Габделҗанов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 3. | «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дип язган бөек галимебез Шиһабетдин | **Татарстан Республикасында Ватанны яклаучылар елын уздыру буенча** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Мәрҗани. Тарихи хәтерне саклау – киләчәк буыннар алдындагы бурычыбыз. Бу безгә буыннар бәйләнешен тирәнтен тоярга, киләчәккә ышаныч белән карарга ярдәм итә. 2025 елда бөтен илебез белән без иң зур бәйрәм – совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 80 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Бу Җиңү, һич арттырмыйча әйткәндә, – безнең иң зур горурлыгыбыз. Җиңүчеләр буыны алдында без түләп бетерә алмаслык бурычлы. Бүгенге көндәге уңышларыбыз ветераннарыбызның җиңү хакына фронтта фидакарьләрчә көрәшүе һәм тылда тырышып эшләве нәтиҗәсендә ирешелде. Ни кызганыч, вакыт агышын туктату мөмкин түгел, Бөек Җиңүнең шаһитләре арабыздан китә бара. Һәр ветеран турында кайгыртуны һәм аларга игътибарны аеруча арттыру зарур. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә Җиңү бәйрәмен билгеләп үтүгә әзерлекне иң югары дәрәҗәдә оештырырга кирәк. Ватан каһарманнары, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм хезмәт батырлары турында хәтерне мәңгеләштерү эшен дәвам иттерү шулай ук бик мөһим. **Бөек Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтү кысаларында, безнең алда торган бурычларның әһәмиятен исәпкә алып, республикада 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итәм.** Үткәненә хөрмәт сакламаганның киләчәге юк. Халкыбызның шанлы үткәне турындагы истәлекләрне кадерләп саклап, буыннан-буынга | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары**<br><br>3.1. Фашист Германиясен Җиңүнең 80 еллыгына багышланган чаралар уздыру, шул исәптән Казан шәһәренең Ветераннар советы каршындагы «Реплика» әдәби-музыкаль театры белән хезмәттәшлектә. | 2024, 2025 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе (Х.Г. Миргалимов) |
| | | 3.2. Беркетелгән сайлау округларында 1941 – 1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чараларда катнашу. | 2025 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| | | 3.3. Ватанны яклаучылар елына багышланган парламент дәресе. | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (И.В. Терентьева), Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Матбугат хезмәте (О.А. Благодарова) |
| | | 3.4. Татарстан Республикасыннан булган хәрби хезмәткәрләргә ярдәм мәсьәләләре буенча кайнар линия телефоны. | 2025 елның феврале | «Мәрхәмәт – Милосердие» депутат төркеме (А.Р. Нәбиева) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тапшыра килү, шулар үрнәгендә илебезнең хөрмәткә лаеклы гражданнарын тәрбияләү – безнең изге бурычыбыз. | 3.5. 2025 елда Татарстан Республикасында Ватанны яклаучылар елын уздыруга багышланган хәйрия концерты. | 2025 елның марты | «Мәрхәмәт – Милосердие» депутат төркеме (А.Р. Нәбиева, О.М. Воронова, С.М. Захарова) |
| | | 3.6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын һәм Татарстанда Ватанны яклаучылар елы чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту мисалында Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү һәм камилләштерү турында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның апреле | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| | | 3.7. «ТНВ» депутат төркеме җыелышында түгәрәк өстәл форматында «Ватанны саклаучыларның, шулай ук Татарстан Республикасы үсешенә өлеш керткән танылган шәхесләрнең истәлеген мәңгеләштерүгә юнәлдерелгән чаралар» мәсьәләсен карау. | 2025 елның II кварталы | «ТНВ» депутат төркеме (А.Р. Габделҗанов) |
| | | 3.8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Махсус хәрби операция ветераннарына ярдәм чаралары турында (социальләштерү, реабилитация, эшкә урнаштыру һәм башкалар)» темасына «Хөкүмәт сәгате». | 2025 елның июле | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (С.М. Захарова) |
| | | 3.9. Татарстан Республикасы Дәүләт | 2025 елның | Татарстан |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Советында «Единая Россия» депутат фракциясе утырышында «Татарстан Республикасында Ватанны яклаучылар елын уздыру йомгаклары турында»гы мәсьәләне карау. | IV кварталы | Республикасы Дәүләт Советында «Единая Россия» фракциясе (Ю.З. Камалтынов) |
| 4. | Балаларыбыз аңына үтеп керү өчен көрәш барган хәзерге вакытта дошман пропагандасы йогынтысын киметү гаять мөһим. Яшь кешеләрне тискәре йогынтылы берләшмәләргә җәлеп итү, террорчылык оешмаларына тарту омтылышлары һәм аларны җинаятьләр кылуга, шул исәптән наркотик матдәләр житештерүгә һәм таратуга күндерү житди борчылу тудыра.<br>Депутатлар корпусына балигъ булмаганнарны хокук бозу эшчәнлегенә тарткан өчен кырысрак җаваплылык билгеләү буенча тәкъдимнәр кертүен сорап мөрәҗәгать итәм.<br>Тулаем алганда, яшьләр белән эшләү системалы һәм комплекслы башкарылырга тиеш. Бу өлкәдә яшь буын вәкилләре белән мөмкин булганча колачлы эш алып бару – гаять мөһим бурыч. Тагын бер кат әйтәм: үсмерләрнең бер генә категориясе дә игътибардан читтә калмаска тиеш. | 4.1. Социаль сәясәт комитеты утырышында «Балаларны һәм яшьләрне эш белән тәэмин итүне оештыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (С.М. Захарова) |
| | | 4.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның актуаль мәсьәләләре хакында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты (А.А. Чубаров) |
| | | 4.3. Алга таба закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертеп, балигъ булмаганнарны хокукка каршы эшчәнлеккә җәлеп иткән өчен җаваплылыкны көчәйтү буенча федераль закон проектын әзерләү. | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты (А.А. Чубаров) |
| 5. | Иҗтимагый фикер, аеруча яшьләр арасында, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм яңа мәгълүмат каналлары аша тудырыла. Мөхәррирләрнең, журналистларның һәм медиа | 5.1. «2023 ел йомгаклары буенча «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өлкәсенең башка эшлекләләренең һөнәри осталыгы һәм җаваплылыгы җәмгыятьтәге фикри юнәлешләрне тудыручы мәгълүматның сыйфатын һәм дөреслеген билгели. Халыкка тикшерелгән, объектив мәгълүматны үз вакытында җиткерү, ялган хәбәрләр таралуга юл куймау, медиа өлкәсендә халыкның белемен арттыру гаять мөһим. Бу эштә төп роль «Татмедиа» республика агентлыгына йөкләнә. | бюджет учреждениеләре тарафыннан дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында» 2024 елның 6 февралендәге 2324-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үтәү барышы хакында»гы мәсьәләне карау. | | милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| 6. | Ил Президенты тарафыннан 2030 елга кадәр Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында указ кабул ителде. Төп юнәлешләргә, шул исәптән икътисадның нәтиҗәле эшләвен арттыру һәм аны кадрлар белән тәэмин итүгә, цифрлы нигезгә күчү һәм технологияләр өлкәсендә алдынгылыкка ирешүгә, яшәү өчен уңайлы, куркынычсыз инфраструктура һәм нәтиҗәле транспорт системасы булдыруга, әйләнә-тирә мохит һәм экология турында кайгыртуга, кешеләрнең иминлеген һәм сәламәтлеген ныгытуга, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга, шулай ук гаиләләргә ярдәм күрсәтүгә, ана һәм бала мәнфәгатьләрен кайгыртуга кагылышлы яңа илкүләм проектлар эшләнде.<br>Барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарының бурычы – илкүләм проектларда республиканың актив катнашуын һәм аларның үтәлүен тәэмин итү. | 6.1. Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Татарстан Республикасында илкүләм проектларны гамәлгә ашыру барышы турында (Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты карамагындагы мәсьәләләр буенча)» мәсьәләсен карау.<br><br>6.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасында илкүләм проектларны гамәлгә ашыру турында халыкка мәгълүмат җиткерүдә катнашулары. | 2025 елның марты<br><br>2024, 2025 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 7. | 8 сентябрьдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җиденче чакырылышы сайланды. Аның алдында, заман куйган сынауларны исәпкә алып, Россия дәүләтчелеген ныгыту, | 7.1. Халыкны кабул итү:<br>1) сайлау округлары һәм муниципаль районнар, шәһәрләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын | 2024, 2025 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тарихи гаделлекне саклау, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны тәэмин итүгә юнәлтелгән мөһим бурычлар тора.<br>Әшегез белән сез сайлаучыларның ышанычын акларга тиешсез.<br>Киләсе елда Татарстан Республикасы Рәисен, шулай ук җирле үзидарәләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлау булачак.<br>Татарстанның киләчәк үсеше һәм гражданнарның иминлеге дәүләт һәм муниципаль хакимиятнең, депутатлар корпусының бердәм һәм һөнәри осталык югарылыгында эшләвенә бәйле.<br>Халык белән даими бәйләнештә тору, барлык мөрәҗәгатьләргә тиз арада һәм тиешенчә җавап бирү гаять мөһим. Элемтәнең, аралашуның барлык мөмкин булган юлларыннан, шул исәптән социаль челтәрләрне, шулай ук «Халык контроле»н, «Инцидент-менеджмент»ны, Кара-каршы элемтә платформасын да файдаланырга кирәк. | беркетү нигезендә;<br>2) Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның Татарстан Республикасында кабул итү бүлмәсендә;<br>3) «ЕДИНАЯ РОССИЯ» партиясе Рәисе Д.А. Медведевның Татарстан Республикасында Региональ җәмәгать кабул итү бүлмәсендә;<br>4) КПРФ сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге кабул итү бүлмәсендә.<br><br>7.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының гражданнар җыеннарында, сайлаучылар белән очрашуларда катнашулары.<br><br>7.3. Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында «2025 елда Татарстан Республикасы Рәисен һәм җирле үзидарәнең вәкиллекләре органнары депутатларын сайлауларны уздыруны законнар белән һәм оештыру ягыннан тәэмин итү турында»гы мәсьәләне карау. | <br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2024, 2025 еллар дәвамында<br><br><br><br>2025 елның II кварталы | <br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары<br><br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты (А.Г. Хәбибуллин) |
| 8. | Республика милләтара һәм динара тынычлыкны һәм татулыкны саклау һәм ныгыту үрнәге булды һәм булачак. Буыннан-буынга күп гасырлар дәвамында туплана килгән олы тәҗрибәгә таянып, җәмгыятебездәге тотрыклылыкны тәэмин итә торган нигезләрне – рухи һәм әхлакый хәзинәләребезне, милли гореф-гадәтләребезне һәм туган телләрне саклау өчен зур тырышлык куябыз.<br>Традицион дини конфессияләргә ярдәм | 8.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан бәйрәмгә әзерлек һәм аны уздыру турында» темасына «Хөкүмәт сәгате». | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күрсәтүгә һәм динара багланышларны ныгытуга аерым игътибар бирелә. Республика башкаласында Җамигъ мәчетен төзү һәм Казан Богородица монастырен торгызуны дәвам иттерү, шулай ук туган телләрне, мәдәниятләрне һәм гореф-гадәтләрне саклау турында карарлар кабул ителде. Бу юнәлештә Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев, республиканың Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Готыф улы Әхмәтов җитәкчелегендәге махсус комиссия, Татарстан халыклары ассамблеясы, милли-мәдәни берләшмәләр зур эш башкара.<br>Төрле халыкларның милли мәдәниятен якынайтуга Каюм Насыйри зур игътибар биргән. Бу хәзер дә бик актуаль. Киләсе елда без атаклы тел галиме һәм язучының тууына 200 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Юбилей чараларын лаеклы дәрәҗәдә уздыру мөһим. | | | |
| 9. | Россиянең һәм аның төбәкләренең мөселман дәүләтләре белән багланышларын үстерүдә Татарстанның роле елдан-ел арта бара. Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре белән сәүдә-икътисадый, фәнни-технологик, социаль һәм мәдәни элемтәләрне ныгытуны дәвам иттерергә кирәк.<br>Якын чит илләр һәм Россия төбәкләре белән икътисадый һәм мәдәни партнерлыкны ныгыту өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. | 9.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеге турында» темасына «Хөкүмәт сәгате». | 2025 елның апреле | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты (А.Г. Хәбибуллин) |
| 10. | Кытай партнерларыбыз белән үзара хезмәттәшлекне, беренче чиратта сәүдә-икътисадый һәм инвестицияләр кертү өлкәләрендә, киңрәк җәелдерү мөһим. Ел саен | 10.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы эшендә катнашулары. | 2025 елның III кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Казанда уздырыла торган «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы бу өлкәдә отышлы эшчәнлек мәйданчыгы булырга тиеш. | | | |
| 11. | Ватандашлар белән эшләү, шул исәптән безнең предприятиеләр һәм оешмалар белән берлектә сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне ныгыту һәм яшьләр проектларын үстерү зур игътибар таләп итә.<br>Бу эштә Бөтендөнья Татар конгрессы төп роль уйный. Үзгәрүчән шартларны исәпкә алып, аңа милләттәшләр белән эшләү формаларын камилләштерүгә әһәмият бирергә кирәк.<br>Халыкара һәм төбәкләр юнәлешләрендә парламентара хезмәттәшлекне үстерүне дәвам иттерү зарур. | 11.1. Парламентара хезмәттәшлек кысаларында Идел буе округындагы Россия Федерациясе субъектларының берәр закон чыгару органының профильле комитеты белән уртак күчмә утырыш уздыру. | 2025 елның июне | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты<br>(А.Р. Зарипов) |
| 12. | Барлык тармак предприятиеләренең өзлексез һәм нәтиҗәле эшен тәэмин итү төп бурычларның берсе булып кала. Хакимият органнарына бизнеска, шул исәптән ярдәм чараларыннан файдалануда, продукция һәм комплектлау җиһазларын китерү логистикасын төзүдә, инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда, импортны алмаштыру производстволарын оештыруда, яңа технологияләрне кулланышка кертүдә һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруда мөмкин булганча зур ярдәм күрсәтүне туктатмаска кирәк. | 12.1. Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Кече һәм урта бизнес, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокуклары гарантияләрен тәэмин итү, административ киртәләрне киметү өлкәсендәге законнарны камилләштерү проблемалары һәм перспективалары турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>12.2. «Казан май комбинаты» акционер җәмгыятендә Бюджет, салымнар һәм финанс комитетының күчмә утырышында региональ салым ташламаларыннан нәтиҗәле файдалану турындагы мәсьәләне карау. | 2025 елның апреле<br><br>2025 елның III кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты<br>(Р.Г. Хөсәенов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты<br>(Л.А. Якунин) |
| 13. | Тармакның әйдәп баручысы – «Татнефть» | 13.1. Экология, табигатьтән файдалану, | 2025 елның | Татарстан |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | компаниясе – үзенең фәнни базасын үстерү, нәтиҗәләр бирәчәк дип саналган юнәлешләргә – биотехнологиягә, энергиянең альтернатив чыганакларына инвестицияләр кертү, кадрлар әзерләү өчен шартлар булдыру (Югары нефть мәктәбе, «Мәктәп биолабораторияләре», «Татнефть ТИҮ вәкилләре»), үз экология программасын гамәлгә ашыру буенча актив эшләвен дәвам итә. | агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Нефть, газ, химия комплексы предприятиеләренең берсе мисалында атмосфера һавасын, җирләрне, су объектларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының табигатьне саклау законнарының үтәлеше хакында»гы мәсьәләне карау. | июне | Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты (А.К. Хамаев) |
| 14. | Аддитив технологияләр, пилотсыз транспорт һәм ясалма интеллект өлкәсендә республикада компетенцияләр буенча өч фәнни-координация база үзәген төзи башладык. | 14.1. Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының күчмә утырышында «Пилотсыз транспорт чараларын куллану һәм үстерү» мәсьәләсен карау *(«Иннополис» университеты базасында).* | 2024 елның ноябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 15. | «Татэнерго» компаниясенә Зәй дәүләт район электр станциясенең һәм Чаллы җылылык-электр үзәгенең генерацияләү егәрлекләрен яңартып коруга юнәлдерелгән тиешле карарларны кабул итүне тәэмин итү зарур.<br>«Челтәр компаниясе» быел «Сокуры»дагы 110 кВ ярдәмче станциясен төзү һәм 220 кВ «Тойма-2» ярдәмче станциясен үзгәртеп кору эшләрен төгәлләячәк. Система төзүче территориаль челтәр оешмасы буларак, «Челтәр компаниясе»нә, әйдәүче сәнәгать предприятиеләрен электр энергиясе белән ышанычлы тәэмин итү өчен, үз статусын югалткан территориаль челтәр оешмалары карамагындагы электр челтәрләре объектларын берләштерүне тәэмин итәргә кирәк. | 15.1. Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын булдыруда закон чыгару аспектлары» мәсьәләсен карау. | 2024 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 16. | Республикада 2019 – 2028 елларга газлаштыру буенча төбәк программасын (гомуми финанслау | 16.1. Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Йорт | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күләме 23,9 млрд сум тәшкил итә) үтәү дәвам иттерелә. «Газпром» акчасы хисабына 3,4 млрд сумлык Газ кертүне үстерү программасы гамәлгә ашырыла. Россия Президенты йөкләмәсе нигезендә үтәлә торган газ кертү программасы кысаларында «Газпром трансгаз Казань» компаниясе 2021 елдан башлап газүткәргеч торбаларны 26 меңнән артык йорт хуҗалыгына китереп җиткерде. Быел Владимир Владимирович Путин тарафыннан коммерциячел булмаган бакча ширкәтләренә газ уздыру турында карар кабул ителде. | хуҗалыкларын социаль газлаштыру программасын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау *(«Газпром межрегионгаз Казань» акционер җәмгыяте базасында).*<br><br>16.2. Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына мониторинг ясау хакында»гы мәсьәләне карау. | <br><br><br><br><br><br>2025 елның июле | Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты (А.К. Хамаев) |
| 17. | Предприятиеләрнең, транспорт һәм социаль инфраструктура объектларының сәнәгать һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлыгын тәэмин итү мөһим мәсьәлә булып кала. Хокук саклау органнарының килешеп эшләве нәтиҗәсендә террорчылык һөҗүмнәре үз вакытында ачыла һәм туктатыла. Предприятиеләр җитәкчеләренә бу мәсьәләдә сизгерлекне киметмәскә кирәк, өстәмә саклык чаралары күрелергә тиеш. Гомумән алганда, иминлекне тәэмин итү мәсьәләләре бүген алгы планга чыга. Республикада бик күп чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә алар аеруча актуальлек ала. Бу эш өчен төп җаваплылык Эчке эшләр министрлыгына йөкләнә. Бүгенге көндә кадрларга җитди кытлык булу сәбәпле, | 17.1. Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында җәмәгать иминлеге өлкәсендәге законнарны камилләштерүгә юнәлдерелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын карау.<br><br>17.2. Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча законнарны гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2024 елның ноябре<br><br><br><br><br><br><br><br>2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты (А.Г. Хәбибуллин)<br><br><br><br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты (А.А. Чубаров) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Министрлыкта эшләүче хезмәткәрләргә эш күләме икеләтә һәм хәтта өчләтә арта. | | | |
| 18. | Республика Хөкүмәтенә депутатлар корпусы белән берлектә законнар нигезендә эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә матди ярдәм күрсәтү мөмкинлеген карау мәсьәләсен эшләүне йөклим. Шулай ук республика предприятиеләренә һәм оешмаларына бу мәсьәләдә ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать итәм. Эчке эшләр министрлыгының эше – ул, беренче чиратта, безнең һәм якыннарыбызның иминлеге. | 18.1. Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә Россия Федерациясе субъектының һәм муниципаль берәмлекләрнең бюджет акчаларын җәлеп итү мөмкинлеге белән матди ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча, алга таба Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертеп, закон чыгару инициативасы әзерләү. | 2025 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты (А.А. Чубаров), Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин) |
| 19. | Предприятиеләрнең киләчәк технологик үсешенең нигезен фән һәм югары квалификацияле кадрлар тәшкил итә. Фәнни-технологик үсеш елы кысаларында республикада Татарстанның белем бирү һәм фәнни тикшеренү мөмкинлекләрен арттыру, яшь галимнәрне тармакта эшләүгә җәлеп итү һәм аларга ярдәм күрсәтү, шулай ук фән һәм сәнәгать хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча гаять мөһим эшләр башланды. Бирeдә, беренче чиратта, Владимир Владимирович Путин йөкләмәсе нигезендә төзелгән Алдынгы инженерлык мәктәпләрен үстерү турында сүз бара. Республикада эйдәүче университетлар һәм тармакка бәйле система төзүче предприятиеләр базасында шундый алты проект гамәлгә ашырыла. Хөкүмәткә Фәннәр академиясе белән берлектә кызыксынган сәнәгать предприятиеләре белән | 19.1. Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасында «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проектын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәттәшлектә алдынгы яңа инженерлык мәктәпләрен төзү буенча тәкъдимнәр әзерләргә кирәк.<br>Гомумән алганда, яңа шартларга җайлашырга сәләтле инженерлар әзерләү югары технологияле эшкуарлыкның үсеше белән тыгыз бәйләнештә алып барылырга тиеш. Алдынгы инженерлык мәктәбен тәмамлап чыгучы һәрбер егет-кызның диплом эшенең, квалификация проектының баштан ук предприятиеләребез һәм үсеш институтлары катнашында яңа стартап булу мөмкинлеген күздә тотып әзерләнүе шарт. | | | |
| 20. | Фәнни тикшеренүләргә һәм эшләнмәләргә чыгымнарны арттыру буенча ил Президенты тарафыннан куелган бурычларны үтәү өчен икътисадның реаль секторының илдәге технологик яңалыкларга ихтыяҗын булдыруга карашны катгый үзгәртергә, акыл эшчәнлеге нәтиҗәләрен һәм матди булмаган активларны хуҗалык эшләрендә куллануга активрак кертү, фән һәм тикшеренүләр өлкәсенә талантлы белгечләрне һәм өметле кадрларны җәлеп итү өчен шартлар тудырырга кирәк. | 20.1. Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасы сәнәгатенең әһәмиятле тармакларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, компетенцияләр үзәкләрен булдыру чаралары турында»гы мәсьәләне карау *(Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе базасында).* | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| | | 20.2. Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы турында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| 21. | Безнең мөһим бурычыбыз – предприятиеләрне хезмәт ресурслары белән тәэмин итү.<br>Мигрантлар санын киметү әлеге өлкәдә вазгыятьнең тагын да кискенләшүенә китерергә мөмкин. Зур предприятиеләребезнең уңай тәҗрибәсен исәпкә алып, чикләүләр кертү | 21.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Миграция сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасында башкарылган эш турында» темасына «Хөкүмәт сәгате». | 2024 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | урынына мигрантлар белән эшне тәртипкә салырга һәм аны комплекслы төстә алып барырга кирәк. Мигрантларның торак мәсьәләләрен хәл итү һәм аларны укытуны оештыру белән беррәттән, аларның хокук тәртибен саклавын, безнең территориядә яшәгән чорда үз-үзен тоту кагыйдәләрен, шулай ук хезмәт шартнамәләре таләпләрен үтәвен контрольдә тотарга кирәк.<br>Дәүләт Советы депутатларына Дәүләт Думасы депутатлары белән берлектә чит ил гражданнарының яисә гражданлыгы булмаган затларның Россия Федерациясе территориясендә яшәү режимын тәэмин итү һәм мигрантларга эшкә урнашырга ярдәм итүче рекрутинг агентлыклары эшчәнлеген җайга салу өлкәсендә, шулай ук чит ил гражданының хезмәт шартнамәсе таләпләрен үтәмәгән өчен хезмәт эшчәнлеге алып баруга патентын алу турында тиешле закон проектлары әзерләүләрен сорап мөрәҗәгать итәм. | 21.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Россия Федерациясенең яңа миграция сәясәтен исәпкә алып, республика территориясендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга җәлеп ителгән чит ил эшче көчләрен җәлеп итүне квоталаштыруның актуаль проблемалары турында» темасына «Хөкүмәт сәгате».<br><br>21.3. Чит ил гражданнарының яисә гражданлыгы булмаган затларның Россия Федерациясе территориясендә яшәү режимын тәэмин итү һәм мигрантларга эшкә урнашырга ярдәм итүче рекрутинг агентлыклары эшчәнлеген җайга салу өлкәсендә, шулай ук чит ил гражданының хезмәт шартнамәсе таләпләрен бозган өчен хезмәт эшчәнлеге алып баруга патентын алу турында федераль закон проектын әзерләү һәм аны алга таба закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү. | 2025 елның июне<br><br>2025 елның II кварталы | (А.А. Чубаров)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты (А.А. Чубаров) |
| 22. | Моннан тыш, Хөкүмәтебезгә предприятиеләребез, югары уку йортлары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары белән берлектә мәктәпләрдә системалы төстә укучыларга һөнәри юнәлеш бирү эшен оештырырга кирәк. Соңгы елларда 9 сыйныфны тәмамлаучыларның саны артуын исәпкә алганда, бу эш аеруча мөһим булачак.<br>Икътисадның реаль секторы белән мәгариф | 22.1. Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасында «Профессионалитет» федераль проектын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның мае | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләренең үзара хезмәттәшлек алып баруына уңышлы үрнәкләр дә бар. «Татнефть», «Газпром», «СИБУР», «Челтәр компаниясе», «Татэнерго» оешмалары һәм Зеленодольскиның Горький исемендәге заводы нәкъ менә шундыйлардан. | | | |
| 23. | Урта һөнәри белем бирү системасын яңартып кору таләп ителә. Көллиятләрдә уку абруйлы саналырга тиеш. Белгечләрне, предприятиеләрнең һәм инвестиция проектларының ихтыяҗларын исәпкә алып, максатчан рәвештә әзерләргә кирәк. | 23.1. Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Төзелеш тармагы өчен кадрлар әзерләү системасын камилләштерү» мәсьәләсен карау *(Казан төзелеш, архитектура һәм шәһәр хуҗалыгы көллияте базасында).* | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 24. | Аерым затларны инвестицияләр кертүгә (беренче чиратта технологик секторга) кызыксындыру максатларында югары процент ставкалары билгеләнү шартларында министрлыклар, ведомстволар һәм җирле үзидарә органнары ташламалы өстенлек бирүче зоналарның, сәнәгать парклары инфраструктураларының һәм тиешле ярдәм инструментларының максималь дәрәҗәдә файдаланылуын тәэмин итәргә тиеш. | 24.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның актуаль проблемалары, инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасында норматив хокукый базаны камилләштерү юллары хакында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| 25. | Кече һәм урта эшкуарлыкның үсешен тәэмин итү өчен гамәлдә булган ярдәм чараларының нәтиҗәлелеген арттырырга, бизнес таләпләрен исәпкә алып, яңа алымнар уйлап табарга кирәк. Биредә өстенлекле өлкәләргә: сәнәгать, туристлык, креатив индустрия тармакларына һәм кече технологик компанияләргә аеруча зур игътибар бирү зарур. | 25.1. Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Татарстан Республикасында креатив индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы законы проектын карау. | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| 26. | Соңгы елларда республикада үзмәшгульләрнең режимын билгеләү максатларында уздырылган | 26.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Татарстан | 2025 елның ноябре | Татарстан Республикасы Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тәҗрибә кысаларында зур эш алып барыла. Безнең бурыч – аларның икътисадый активлыкларын тәэмин итү һәм киләчәктә бизнесның бер категориясеннән икенче категориясенә күчүенә ярдәм итү. | Республикасында «Һөнәрдән керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча тәҗрибә уздыру нәтиҗәләре турында»гы мәсьәләне карау. | | Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин) |
| 27. | Без системалы рәвештә авыл хуҗалыгы комплексын үстерү белән шөгыльләнүне дәвам итәбез. Вазгыятьнең нинди генә катлаулы булуына карамастан, Татарстанда ярдәм күрсәтү чараларының барысы да сакланды. Шулай итеп, быел гына да техниканы яңартуга 1,8 млрд сум, туфракның уңдырышлылыгын яхшыртуга 1 млрд сумга якын акча бүлеп бирелде. Фәнни-техник үсеш елында без фәнни үзәкләребездән үзебездә җитештерелгән орлык селекциясе эшендә тәгаен нәтиҗәләр көтәбез. Соңгы биш елда авыл хуҗалыгы культураларының яңа 33 сорты булдырылды һәм җирле селекция сортының 20 төренә гариза бирелде.<br>Быел без авыл хуҗалыгында инновация мохите формалаштыру максатларында Лаеш районында Агробиотехнопарк ачтык. Ул алдынгы тәҗрибәләрне сынау буенча федераль дәрәҗәдәге компетенцияләр үзәге булырга тиеш.<br>Республикабыз – терлекчелек төбәге. Сөт җитештерү буенча илебездә ул беренче урында.<br>Безнең бурыч – яңа инвестиция компанияләрен җәлеп итеп, терлекчелек продуктлары җитештерү күләмнәрен арттыру. Кызганычка каршы, кайбер районнарда терлекчелек өлкәсендә хәлләр көннән-көн начарая бара. | 27.1. Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәү турында»гы мәсьәләне карау. | квартал саен | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты (А.К. Хамаев) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Район башлыкларына Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә тиешле чаралар күрү таләп ителә.<br>Үзебездә җитештерелгән продуктларны эшкәртүне тәэмин итү – бик мөһим мәсьәлә.<br>Бүгенге көндә республикада сөтнең 87 проценты эшкәртелә. Биш ел элек әлеге күрсәткеч 50 процентка да җитми иде. Безнең алда торган бурыч – ит һәм үсемлекчелек продуктларын эшкәртү тармагын үстерү.<br>Тышкы базарларга чыгу шулай ук бик мөһим. Чит илләр белән сәүдә алып баруда Татарстанны Идел буеның чын мәгънәсендә төп ашлык җитештерү үзәге итеп таныту өчен бездә барлык шартлар да бар. Әлеге юнәлештә күп кенә киң колачлы проектлар тормышка ашырыла.<br>Чит илләргә сатуга чыгарылган хәләл продуктларның күләмен тагын да арттыру өчен зур резервыбыз бар. Узган ел ул ике тапкырга диярлек артты.<br>Авыл хуҗалыгы ярминкәләрен уздыруны дәвам итү шулай ук бик мөһим. | | | |
| 28. | Безнең бурыч – үсештә тукталып калмаска, ясалма интеллект һәм цифрлы технологияләр өлкәсендә киләчәктә Татарстанны Россиянең иң алдынгы үзәге итеп таныту юнәлешендә күп көч куярга кирәк.<br>Хөкүмәтебезгә 2030 елга кадәр алгарышлы ИТ-карарлар комплекслы программасын эшләүне йөклим. | 28.1. Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Татарстан Республикасында «Цифрлы икътисад» илкүләм проектын гамәлгә ашыру барышы турында, шул исәптән икътисадны һәм дәүләт идарәсен цифрлаштыру өлкәләрендә» мәсьәләсен карау. | 2025 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| 29. | Шәһәр янындагы ял инфраструктурасын үстерү буенча ике туристлык-рекреация кластеры – | 29.1. Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында | 2025 елның сентябре | Татарстан Республикасы Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Кама Тамагында һәм Зәңгәр күлләрдә төзекләндерү эшләре тәмамланды, Алексеевск районында Изге чишмә яңартыла, Иделнең уң як ярыннан гаҗәеп матур урыннар буйлап җәяүле маршрут – «Идел сукмагы» проекты эшли башлады, республиканың төрле муниципаль берәмлекләрендә 52 заманча глэмпинг барлыкка килде.<br>Тагын бер мөһим этап – автомобильләрдә сәяхәт итүчеләр өчен уңайлы шартлар (автокемпинглар, табигать кочагында туктап ял итү урыннары, сервис зоналары), шулай ук сулыклар янында ял итү урыннары булдыру зарур. | «Татарстан Республикасында туристлык тармагын үстерүне законнар белән тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре турында»гы мәсьәләне карау. | | Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| 30. | Без, һичшиксез, халыкның яшәү шартларын яхшыртуга юнәлтелгән программаларны тормышка ашыруны дәвам иттерәчәкбез. Республикада яшәүче һәр кеше өчен мөһим булган торак-коммуналь хуҗалык тармагына аерым игътибар биреләчәк. Коммуналь инфраструктура объектларының торышы көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Челтәрләрдәге аварияләрнең саны, шулай ук коммуналь хезмәтләрнең сыйфатына карата гражданнар шикаятьләре – моның ачык дәлиле.<br>Илебез Президенты В.В. Путинның карары нигезендә узган елдан коммуналь инфраструктураны яңартып кору программасы эшли башлады. Аңа өстәмә буларак, 2025 елдан без коммуналь инфраструктураны яңартып кору буенча яңа республика программасын гамәлгә ашыра башлау турында карар кабул иттек. Төзелеш министрлыгына аеруча проблемалы | 30.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Социаль һәм инфраструктура объектларын параллель үстерүнең (төзүнең) яңа хокукый инструментларын булдыру» темасына «Хөкүмәт сәгате».<br><br>30.2. Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Татарстан Республикасы территориясендә коммуналь инфраструктураны модернизацияләү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау *(республика муниципаль районнарының берсе мисалында).*<br><br>30.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Тарифлар белән җайга салуны цифрлаштыру» мәсьәләсен | 2025 елның октябре<br><br>2025 елның ноябре<br><br>2025 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | территорияләрне һәм объектларны билгеләп, тиешле тәкъдимнәр әзерләргә кирәк булачак. | карау. | | сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 31. | Юл һәм транспорт инфраструктурасы белән берлектә соңгы елларда республикада логистика инфраструктурасы да зур үсеш кичерә. Төньяк – Көньяк һәм Көнбатыш – Көнчыгыш халыкара транспорт коридорлары аша йөк ташу өчен төп елга порты булган Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәген, OZON, Wildberries, «Яндекс» логистика үзәкләрен, шулай ук «Бер географик пояс – бер юл» проектын тормышка ашыру кысаларында республиканың Тукай районында мультимодаль үзәк төзү – моңа ачык дәлил.<br>Республиканың географик яктан уңайлы урнашуы, юл, транспорт һәм логистика инфраструктурасының үсеше аны Идел буеның, Төньяк – Көньяк һәм Көнбатыш – Көнчыгыш транспорт коридорының төенләнеш үзәге дип танырга нигез бирә.<br>Татарстан җитештерүчеләренең мөмкинлекләреннән тагын да нәтиҗәлерәк файдалану максатында логистика эшчәнлеген координацияләү өчен безгә логистика географиясендәге уңай үзгәрешләргә өстәмә рәвештә анализ уздырырга кирәк. | 31.1. Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Елга транспортында транспорт логистикасы проблемалары һәм перспективалары» мәсьәләсен карау *(Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге мисалында, Свияжск шәһәре).* | 2025 елның июне | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 32. | Республикада мәгариф өлкәсенә аеруча зур игътибар бирелә. Ә ул, билгеле булганча, балалар бакчасыннан башлана.<br>Укытучысыз мәктәп ул – гади бер бина гына. | 32.1. «Белем бирү һәм тәрбия өлкәсендәге проблемалар турында» темасына түгәрәк өстәл уздыру. | 2024 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Без моны бик яхшы аңлыйбыз. Белем һәм тәрбия бирү процессында мөгаллим-остазларыбыз төп эшне башкара. Көчле укытучы гына яхшы белем бирә ала. Педагогик кадрлар әзерләүгә һәм, тулаем алганда, укытучыларның абруен һәм дәрәҗәсен күтәрү мәсьәләсенә аерым игътибар бирергә кирәк. | 32.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «2024 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында»гы мәсьәләне карау | 2025 елның мае | (Х.Г. Миргалимов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| 33. | Кеше өчен иң зур байлык – аның гомере һәм сәламәтлеге. Яшәеш сыйфаты сагында медицина хезмәткәрләре җаваплы роль уйный. Сәламәтлек саклау өлкәсендә заманча җиһазландырылган хастаханәләр һәм югары технологияле медицина үзәкләре төзү эшен дәвам иттерәбез. Һәр ел саен 100 дән артык медицина учреждениесе төзекләндерелә.<br>Шуның белән беррәттән, медицина ярдәмен алу мөмкинлекләрен арттыру һәм авыруларны профилактикалау юнәлешендә дә зур эш алып барыла. | 33.1. «Сәламәтлек саклауда проблемалар турында» темасына түгәрәк өстәл уздыру.<br><br>33.2. «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында хисап хакында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның марты<br><br>2025 елның апреле, августы, октябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе (Х.Г. Миргалимов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин) |
| 34. | Репродуктив система авыруларын вакытында ачыклау максатларында 15 – 17 яшьлек яшүсмерләргә профилактик тикшеренүләр уздырыла, шулай ук 10 муниципаль берәмлектә диспансеризациянең яңа юнәлеше – ир-атларның һәм хатын-кызларның репродуктив сәламәтлеген бәяләү буенча пилот проект эшли башлады. Аны бөтен республика буенча дәвам итәргә кирәк. Демография – катлаулы, ләкин зур әһәмияткә ия мәсьәлә. | 34.1. Социаль сәясәт комитетының күчмә утырышында «Яшүсмерләргә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турында»гы мәсьәләне карау *(Республика балалар клиник хастаханәсе базасында).* | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (С.М. Захарова) |
| 35. | Эшләребез күркәм нәтиҗәләр бирә. Бүгенге көндә республикада системалы рәвештә физик | 35.1. Социаль сәясәт комитеты утырышында «Физик культура һәм спорт белән | 2025 елның июне | Татарстан Республикасы Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр өлеше 63 проценттан артып китте, ә 2030 елга әлеге күрсәткечне 75 процентка җиткерү зарур. Районнарда велосипедчылар өчен юллар һәм спорт белән шөгыльләнү өчен ачык мәйданчыклар рәвешендә спорт корылмаларының яңа төрләрен булдыру зарур. | шөгыльләнү өчен шартлар тудыру турында»гы мәсьәләне карау *(Татарстан Республикасы муниципаль районнарының берсе мисалында).* | | Советының Социаль сәясәт комитеты (С.М. Захарова) |
| 36. | Татарстанда мәдәният өлкәсенә аерым игътибар бирелә.<br>Агымдагы ел бигрәк тә безнең театрлар өчен үзенчәлекле. Быел без Галиәсгар Камалның, Марсель Сәлимҗановның, Шәриф Камалның юбилей даталарын, Казан операсының 50 еллыгын билгеләп үтәбез.<br>Галиәсгар Камал исемендәге театрның яңа бинасы төзелеп килә. Ул гади театр гына түгел, ә шулай ук һәркем өчен ачык мәйдан һәм бөтен иҗади көчләрне җәлеп итү үзәге булырга тиеш.<br>Тарихи-мәдәни мирасны саклауда музейлар һәм музей мәйданнары мөһим урын тота. Аларның мөмкинлекләреннән, башка өлкәләр – беренче чиратта мәгариф һәм туристлык өлкәләре белән кушылуын тәэмин итеп, тулысынча файдаланырга кирәк.<br>Гомумән алганда, берьюлы берничә юнәлешне – музей, китапханә, театр, клуб эше һәм мәгариф өлкәсен берләштергән комплекслы мәдәният үзәкләрен булдыру мәсьәләсен тирәнтен тикшереп эшләү ихтыяҗы тәмам өлгереп җитте. Шушы ук үзәкләрдә архитектура, мәдәни мирас ядкарьләрен саклау эшчәнлеге тупланырга тиеш. Мисал өчен муниципальара үзәк булып торган Алабуга музей-тыюлыгын бу өлкәдә күркәм үрнәк буларак күрсәтергә мөмкин. | 36.1. Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасында музей эшен үстерү турында»гы мәсьәләне карау. | 2025 елның ноябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 37. | Тормыш алдыбызга яңадан-яңа бурычлар куя. Безнең әле күп эшләр башкарасы бар. Иң мөһиме – без бу бурычларны ничек хәл итәргә икәнен беләбез. Ышанам, без бергә барысына да ирешербез.<br>Тормышның ни дәрәҗәдә тиз үзгәрүен барыбыз да күрәбез. Әмма иң әһәмиятлесе – безне берләштерә торган туган җирне, Ватанны ярату һәм аның алгарышы өчен ихлас йөрәктән тырышып эшләү теләге үзгәрешсез кала. | 37.1. Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы нигезләмәләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы органнарының граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеге. | 2024, 2025 еллар дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |